**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 март № 139

г. Казань

2015 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү турында

Тискәре табигый-климат шартлары барлыкка килгән чорда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары (алга таба – төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары) конструкция элементларының күтәреп тору сәләте кимүгә юл куймау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне кертергә:

2015 елның 15 апреленнән 14 маена кадәрге чорда – төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларыннан узучы, күчәрләргә төшә торган рөхсәт ителгән авырлыклары бу карарның 2 нче пунктында билгеләнгән иң чик күрсәткечләрдән артып киткән йөкле һәм йөксез транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү (алга таба – язгы чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү);

2015 елның 20 маеннан 31 августына кадәрге чорда – «Татарстан Республикасының Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе билгеләнгән тәртиптә бирә торган мәгълүматлар нигезендә һаваның көндезге температурасы күрсәткечләре 32°C тан югарырак булганда асфальт-бетон түшәлгән төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларыннан авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү (алга таба – җәйге чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

бу карарның 1 нче пунктындагы икенче абзацта билгеләнгән чорга транспорт чарасының һәр күчәренә төшә торган рөхсәт ителгән иң чик авырлыкларның түбәндәге күрсәткечләрен:

бер күчәрлегә – 6,0 тонна;

ике күчәрле арбага – 5,0 тонна;

өч күчәрле арбага – 4,0 тонна.

3. Хәрәкәтне вакытлыча чикләү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

язгы чорда – «Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан Россия Федерациясенең юл хәрәкәте кагыйдәләре белән күздә тотылган 8.20.1 һәм 8.20.2 «Транспорт чарасы арбасы тибы» дигән өстәмә мәгълүмат билгеләре (табличкалары) белән «Транспорт чарасы күчәренә төшә торган массаны чикләү» дигән 3.12 юл билгесен кую юлы белән;

җәйге чорда «Татарстан Республикасының Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе мәгълүматлары буенча һаваның көндезге температурасы күрсәткечләре 32°С тан югарырак булганда – «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан «Хәрәкәтнең махсус шартлары» графасына күчәрләренә төшә торган авырлыгы Россия Федерациясе территориясендә билгеләнгән күчәргә төшә торган авырлыклардан артып киткән транспорт чаралары, төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан авыр йөк ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары хәрәкәтенә махсус рөхсәтне, «Җәйге чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү кертелгәндә хәрәкәт 22.00 сәгатьтән сәгать 10.00 га кадәр рөхсәт ителә» дигән язуны кертү юлы белән;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 31 май, 372 нче карары белән расланган Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә.

4. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

«Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә - Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда, шул исәптән транспорт чаралары авырлыгын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда авырлыкны һәм габаритларны тикшерүдә тоту постларында транспорт чараларын үлчәүне тәэмин итүне;

«Татарстан Республикасының Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә - Татарстан Республикасы буенча көндезге вакытларда була торган һәм бу җәйге чорда фаразланучы һава температурасы турында Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә хәбәр итеп торуны.

5. Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

2015 елның 15 мартына кадәр Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы Рәсми порталы» Татарстан Республикасы

дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында язгы һәм җәйге чорларда вакытлыча чикләүләр кертү турында мәгълүмат урнаштырырга;

«Татарстан Республикасының Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе бирә торган мәгълүматлар нигезендә һаваның көндезге температурасы күрсәткечләре 32°С тан югарырак булганда юл хәрәкәтендә катнашучыларның җәйге чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү шартларын үтәүләрен тикшерүдә тоту зарурлыгы турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә мәгълүмати хатлар җибәрергә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«2014 елда Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү турында» 2014 ел, 15 март, 155 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елда Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү турында» 2014 ел, 15 март, 155 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2014 ел, 28 март, 196 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елда Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү турында» 2014 ел, 15 март, 155 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 14 апрель, 247 нче.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\139.doc